# ЗИНҺАР ӨЧЕН, КЕРМӘ ТӨШЛӘРЕМӘ

*Резеда Әхиярова көе*
*Разил Вәлиев шигыре*

Зинһар өчен, кермә тешләремә!
Мин бит сине күптән оныттым.
Җәй җилләре күптән, күптән агарттылар,
Тараттылар сагыш болытын.

Зинһар өчен, кермә төшләремә...
Уянам да никтер боегам.
Әйтерсең лә, су алмакчы булам
Күптән кипкән сусыз коедан.

Зинһар өчен, кермә тешләремә...
Таң атуга төшләр өзелә.
Көннәремне, елларымны алдың,
Төннәремне калдыр үземә.

Зинһар өчен, кермә төшләремә...
Үртәмәче, көлмә ерактан.
Сине түгел, мин бит яшьлегемне
Шулай сагынам, шулай яратам.

Зинһар өчен, кермә төшләремә...
Минем хәлгә кемнәр тешенә?
...Сөям хәзер бары, бары хыялымда,
Яшим хәзер бары төшемдә.